Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № № XIII-4**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 16 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турында

«Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турында кушымта итеп бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгына әлеге карарны тормышка ашыру максатларында муниципаль хокукый актлар кабул итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының бюджет, финанслар, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2016 елның 16 ноябрендәге
XIII-4 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турында**
**Нигезләмә**

I.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон белән җирле үзидарә органнары компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасының «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең (алга таба - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы) муниципаль-хосусый партнерлыкта катнашу максатларын, рәвешләрен һәм шартларын билгели, шулай ук муниципаль берәмлекнең муниципаль-хосусый партнерлыкта катнашуының аерым мәсьәләләрен җайга сала.

1.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы, муниципаль хокукый актлар, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә тормышка ашырыла.

1.3. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

II. Муниципаль-хосусый партнерлыкның максатлары

Муниципаль-хосусый партнерлыкның максатлары түбәндәгеләр:

1) социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларыннан файдаланып, кулланучыларга күрсәтелә торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең үтемлелеген ( һәркем өчен мөмкин булуын) арттыру һәм аларның сыйфатын күтәрү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль

районының социаль, инженерлык һәм башка инфраструктура объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә, модернизацияләүгә яисә эксплуатацияләүгә хосусый инвестицияләр җәлеп итү исәбенә;

2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милкендәге мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген тәэмин итү.

## III. Муниципаль-хосусый партнерлык принциплары

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык түбәндәге принципларга нигезләнә:

1) дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматлардан гайре, муниципаль-хосусый партнерлык турында мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем өчен мөмкин булуы;

2) көндәшлекне тәэмин итү;

3) дискриминация булмау, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү якларының тигез хокуклылыгы һәм аларның закон каршында тигезлеге;

4) муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешү яклары тарафыннан килешү йөкләмәләрен намус белән үтәү;

5) муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү яклары арасында хәвеф-хәтәрләрне һәм йөкләмәләрне гадел бүлү;

6) муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү төзү иреге.

## IV. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль-хосусый партнерлыкта катнашу рәвешләре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль-хосусый партнерлыкта катнашуы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милкендәге мөлкәтне инвестиция процессына җәлеп итү;

2) инвестиция проектларын, шул исәптән җирле әһәмияттәге инвестиция проектларын тормышка ашыру;

3) инновацион проектларны тормышка ашыру;

4) концессион килешүләр төзү;

5)Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше өлкәсендә хезмәттәшлек һәм үзара хезмәттәшлек турында килешүләр төзү;

6) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә башка рәвешләр (мәсәлән, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр булмаган һәм дәүләт яисә муниципаль унитар предприятиеләр булмаган юридик затларга бюджет инвестицияләре; муниципаль милектәге мөлкәтнең залогы; аренда мөнәсәбәтләре; озак вакытлы аренда; уртак юридик затлар булдыру; муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешү нигезендә муниципаль мөлкәтнең залогы; муниципаль-хосусый партнерлык

проектларын гамәлгә ашыруда катнашучы хуҗалык итүче субъектка муниципаль гарантияләр бирү һ.б.).

## V. Муниципаль-хосусый партнерлыкка муниципаль ярдәм рәвешләре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлыкка муниципаль ярдәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

1) салым ташламалары бирү;

2) бюджет инвестицияләре бирү;

3) муниципаль милек булып торучы мөлкәтне арендалау буенча ташламалар бирү;

4) кредиттан файдалануга процент ставкасы өлешен җирле бюджет акчалары исәбеннән субсидияләү;

5) муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүдә билгеләнгән бәяләр (тарифлар) буенча товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) бәяләрне тариф белән җайга салуга һәм товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) реализацияләүгә бәйле чыгымнар яисә алынмаган керемнәр өлешен каплауга җирле бюджет акчалары исәбеннән субсидияләү;

6) устав капиталына инвестицияләр бирү;

7) муниципаль гарантияләр бирү;

8) мөлкәти хокукларны гамәлгә ашыру;

9) мәгълүмати һәм консультация ярдәме;

10) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә башка рәвешләр.

## VI. Муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү объектлары

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү объектлары булып «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законда каралган объектлар тора.

## VII. Муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне әзерләү, төзү, үтәү һәм туктату тәртибе

Муниципаль-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәр әзерләү, аның вәкаләтле органы тарафыннан карау, муниципаль-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында карар кабул итү, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне төзү, үтәү һәм туктату «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү

турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

## VIII.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендәге вәкаләтләре

8.1. Муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы вәкаләтләренә муниципаль-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында карар кабул итү керә, әгәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы гавами партнер булса яисә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырыла (Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырылган очрактан гайре), шулай ук «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставында, муниципаль хокукый актларда, шулай ук әлеге Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

8.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы:

1) гавами партнерның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында, әлеге Нигезләмәнең 8.4 пунктында каралган очраклардан тыш, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы исеменнән чыгыш ясый;

2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 2 өлешендә, әлеге Нигезләмәнең 8.3 пунктында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органын билгели (алга таба – вәкаләтле орган);

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына проектның нәтиҗәлелеген бәяләүне уздыру һәм «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсендәге 2 - 5 өлешләре нигезендә аның чагыштырма өстенлеген билгеләү өчен муниципаль-хосусый партнерлык проектын җибәрә.

8.3. Вәкаләтле орган:

1) муниципаль-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә;

2) муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү төзү хокукына конкурслар уздыру өчен конкурс документациясен гавами партнерга килештерүне гамәлгә ашыра;

3) муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыру мониторингын гамәлгә ашыра;

4) муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыру барышында гавами партнерларның һәм хосусый партнерларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауда ярдәм итә;

5) муниципаль-хосусый партнерлык турында төзелгән килешүләр реестрын алып бара;

6) муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү хакындагы мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итә;

7) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән федераль башкарма хакимият органына муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыру мониторингы нәтиҗәләрен тапшыра;

8) «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставында һәм муниципаль хокукый актларда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

8.4.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары гавами партнерның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы исеменнән чыгыш ясыйлар.